СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа
авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

## Наласа авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**26.01.2016 ел** **№ 12**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, «Референдум уздыру инициативасы турында» 2016 елның 22 гыйнварындагы 11 номерлы карары нигезендә, Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Наласа авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2016 елда Наласа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә (түләү күләме 350 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Жирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Жирлекнең жирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Наласа авыл жирлеге составына керүче юлларга вак таш җәю: Наласа авылы,<br>- Яшьләр ур;<br>- Үзәк ур;<br>- Җиңү ур;<br>- М.Җәлил ур;<br>- М.Вахитов ур.<br>Урта Бирәзә авылы:<br>- Татарстан ур;<br>- М.Вахитов ур. | <br><br><br>90000<br>90000<br>120000<br>60000<br>36000<br><br>30000<br>5000 |
| 2 | Җирләү урыннарын тоту | - Наласа авылында зиратны койма белән тоту | 37200 |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | - Урта Бирәзә авылында чишмә территориясен төзекләндерү | 12000 |
| | | | 480200 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов ур., 64 йорт, ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл жирлеге башлыгы И.Р.Шакирова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НАЛАСИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003095